وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!


# Дин вә Мәгыйшәт

№9 (152). 31 август 2012 / 13-шәүвәл-1433


ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



"Туфанга сөйләрмен дигән уй туды..." ▷3-4◁



КОРЪӘН – Исламның иң төп чыганагы ▷3◁



Гыйбадәт кылганда игътибарым гел читкә юнәлә ▷4◁

## ТАТАРСТАН МӨФТИЕ ИЛДУС ХӘЗРӘТ ФӘИЗНЕҢ БЕЛЕМ КӨНЕ УҢАЕННАН МӨРӘҖӘГАТЕ

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән республикабыз укучыларын, укытучыларын һәм студентларны Белем көне белән котлыйм!**

Тормышта иң зур кыйммәтләрнең берсе - гыйлем. Аң-белем туплап кына без дөньядагы хәлләрне дөрес бәяләргә өйрәнәбез, шуның белән бергә игелекле, яхшы эшләр кылуыбызга ышаныч ныгый, арта. Менә шул сәбәпле дә ислам динендә гыйлем туплауга зур әһәмият бирелә. Рәсүлебез Мөхәммәд (сгв) Сөннәтендә болай диелгән: "Белемгә омтылу - һәр мөселманның бурычы".

1 сентябрь - белем алучыларга да, укытучылар өчен дә аеруча әһәмиятле көн. Ничек һәм кем булып каршы алуыбызга да карамастан, бу бәйрәм барыбыз өчен дә өмет һәм багланышлар көне булып кала. Беренче сыйныфка кергән сабыймы, яки югары уку йортының бишенче курсында укучы студентмы, яисә күп еллар дәвамында балаларга белем биргән тәҗрибәле укытучымы - барысы да 1 сентябрьне яңа үрләр яулау, тәҗрибә туплый башларга этәргеч бирүче бәйрәм кебек кабул итә.

Галимнәр зирәклеге һәм мөгаллимнәрнең тәҗрибәләре аша дөньяны бөтен тулылыгы белән тану мөмкинлеге бар. Бүгенге көндә балаларыбызны рухи-мәдәни кыйммәтләребез ярдәмендә тәрбияләргә шартлар җитәрлек. Республикабызда Исламның зур педагогик дәрәҗәсе, байлыгы, потенциалы һәм тарихи фәнни уңышлары тупланган, без бу мөмкинлекне югалтмаска тиеш. Чөнки балаларыбызның акыл һәм рухи үсешен кайгырту - ул киләчәккә салынган иң уңышлы инвестиция булып тора.

Гыйлем алу омтылышыбыз беркайчан да кимемәсен, чөнки Аллаһы Тәгалә дөньяга иңдергән хикмәт чиксез.

## Владимир Путин Татарстан мөфтие Илдус Фәизгә һәм Вәлиулла Якуповның хатынына бүләк тапшырды

**28 август көнне Россия Президенты Владимир Путин Татарстанга сәфәре кысаларында Болгарда булды. Аны ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, РФ Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Михаил Бабич, республика Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев озатып йөрде.**

Дәүләт башлыгы Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгының төп объектларында, аерым алганда, Болгар шәһәрчегендә, Ак мәчеттә, Истәлекле билгедә булды. Владимир Путинны Болгар музей-тыюлыгы территориясендә алып барыла торган археология казу эшләре барышы белән дә таныштырдылар.

Ак мәчетне караганнан соң Татарстанның дин вәкилләренә дәүләт бүләкләре тапшыру тантанасы булды. ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең фән һәм мәгариф бүлеге мөдире Вәлиулла Якупов гражданлык бурычын башкарганда күрсәткән батырлыгы өчен үлгәннән соң "Батырлык өчен"ордены белән бүләкләнде.

Владимир Путин бүләкне Вәлиулла хәзрәтнең хатыны Галина Авентьевага тапшырды. РФ Президенты республика мөфтие Илдус хәзрәт Фәизгә "Рухи-әхлакый традицияләрне үстерүдә, гражданнар дуслыгын һәм конфессияара хезмәттәшлекне ныгытуда хезмәт куюы өчен "Дуслык" ордены тапшырды.

"Безнең эшчәнлекне югары бәяләвегез өчен рәхмәт. Татарстан мөселманнары һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәте өчен гадәти булмаган вакытта безнең белән бергә булуыгыз бик мөһим. Традицион ислам динен тотучылар өчен тотрыклылыкны саклау төп максат булып тора", - диде Илдус хәзрәт бүләкне алгач.



Владимир Путин үз чиратында, республиканың традицион конфессия эшлеклеләренә рәхмәт белдерде. "Халыкка хезмәт итү авыр. Ачыкланганча, ул әле куркыныч та. Сезнең кебек көчле рухлы кешеләрне сындыру мөмкин түгеллеген беләм. Халыкка һәм уртак Ватаныбызга хезмәт итүегез өчен рәхмәт сезгә", - диде РФ Президенты.

**М.Козловский фотосы "Татар-информ" мәгълүмат агентлыгы**

## ГЫЙЛЕМ ЭСТӘП КЫТАЙГА...

*Гыйлемне бишектән алып ләхеткә кадәр өйрәнегез (Хәдис)*

**Кеше - Аллаһы Тәгаләбез яраткан бар әйберләр арасында иң гаҗәибедер. Кешенең иң серле, иң аз өйрәнелгән өлеше - аның баш мие. Нәкъ менә баш мие кешенең барлык теләк-омтылышлары белән идарә итә, аның нәтиҗәсе буларак, без авыртуны сизәбез һәм башка тоемлау мөмкинлекләренә ия булабыз; уңай тормыш алып бару өчен зарур булган сөйләм сәләтебез, хисләребез, хәрәкәтләнү системабыз өчен дә миебез җаваплы.**

Шунысы гаҗәп, кешенең баш мие нибары 1,5 килограмм гына булса да, ул уйлап табылган теләсә нинди компьютер техникаларыннан күбрәк вазифага ия. Кеше миенең, Аллаһы Тәгаләбез безгә белем тупларга биргән сәләте - тагын да гаҗәбрәк. Кеше мие никадәр күбрәк белем туплауга җәлеп ителгән булса, ул шулкадәр зуррак үсешкә ия була. Киресенчә, "эштән ял итүче" ми, вакытлар үтү белән, атрофиягә дучар була, мәгълүмат туплау мөмкинлеген киметә бара. Гади итеп кенә әйткәндә, ми ул мускуллар кебек, аңа никадәр күбрәк эш йөкләсәң, ул шулкадәр югарырак үсешкә, мөмкинчелеккә ирешә. Кайбер галимнәр, кеше миенең мөмкинлекләре әлегә тулысынча өйрәнелеп бетерелмәгән дип исәплиләр. Һәм дә бу мине, һәрвакыт, Аллаһның рәхмәте безгә никадәр киң булуы, аның безгә, Җир йөзендәге бар җан ияләреннән дә аермалы итеп, гакыл дигән зур байлык бүләк итүе турындагы уйлануларга этәрә иде. Тик без аннан дөрес файдаланабызмы соң? Бу игелекнең кадерен беләбезме? Белем җыярга һәм туры юлдан барырга тырышабызмы?

Кешелек үзенең үсеш дәверендә гаять зур белемнәр туплаган. Кеше галәмдә, океан төбендә, үтеп чыга алмаслык урманнарда, биек тау башларында, билгесез материкларда булган. Фән бүгенге көндә гигант адымнар белән үсеп бара.

Исламда гыйлемгә зур игътибар бирелә. Чөнки, дин өлкәсендә зур белемнәргә ия булган кеше, үзе генә хаталардан сакланып калу түгел, башкаларны да ялгышлардан искәртүгә сәләтле. Мөгаен, бүгенге көндә мөселман кешесе, берваккытта да булмаган кадәр дәрәҗәдә, укымышлы, гыйлемле, күп белемнәргә ия булырга, фикер йөртә белергә тиеш. Массакүләм мәгълүмат чаралары аркасында мөселман образы бүгенге көндә наданлык һәм рәхимсезлек белән ассоциацияләнә, ә бу исә чынбарлыкка һич тә туры килми.

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

**МӨСЕЛМАН ЭШКУАРЛАРЫ АССОЦИАЦИЯСЕНЕҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ ҮТТЕ**

***Казанның Кабан арты мәчетендә Татарстан мөселман эшкуарлары ассоциациясенең чираттагы утырышы булып үтте.***

Киңәшмәдә ассоциациянең рәисе Радик Гафуров һәм башка вәкилләр катнашты. Әлеге чарада оешманың киләсе елга планнары, башка төбәкләр белән хезмәттәшлекнең әһәмиятлелеге, шулай ук яңа бизнес-проектлар булдыру турында фикер алыштылар.

Мөселман эшкуарлары ассоциациясенең киләсе утырышы 2012 елның 4 сентябрендә шулай ук Кабан арты мәчетендә үтәр дип көтелә.

**ИЛДУС ХӘЗРӘТ ФӘИЗ ДАГСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ЛИДЕРЫ СӘЕТ ӘЛ-ЧИРКӘВИНЕҢ ҮЛЕМЕ УҢАЕННАН БЕЛДЕРҮ БЕЛӘН ЧЫКТЫ**

***ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Илдус хәзрәт Фәиз Дагстан мөселманнары лидеры Сәет әл-Чиркәвинең үлеме уңаеннан белдерү белән чыкты.***

"Янә зур югалту кичерәбез. Меңләгән мөселманнарның рухи остазы, мөселманнар арасында, гомумән, җәмгыятебездә зур дәрәҗәгә ия булган, экстремизмга каршы ачыктан-ачык көрәш алып барган дин әһеле Сәет әл-Чиркәви үтерелде. Сәет әл-Чиркәвинең үлеме - мөселман өммәтебез өчен әйтеп бетергесез зур югалту. Татарстан мөселманнары да Дагстан халкы белән бергә хәсрәт кичерә, сыкрана, сызлана. Сәет әфәнденең туганнарының, якыннарының һәм шәкертләренең тирән кайгысын уртаклашабыз.

Шактый катлаулы заманда яшибез. Һәр атнада диярлек безнең арадан иң күренекле дин белгечләре һәм дин әһелләре китә. Мөфтиләр, аларның урынбасарлары, имамнар, мәгърифәтчеләребезнең гомерләрен өзүдән дә курыкмыйлар. Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә, Үзенең динен үстереп, хакыйкать нурын таратучыларның гомерләренә кизәнгән кешеләрне тугры юлга күндерсә, иман бирсә иде.

Террорчыларның милләте дә, дине дә юк. Кеше гомерен өзү алар өчен берни дә тормый. Шуңа да илебезнең барлык гражданнарын да экстремизм һәм террорчылыкка каршы торырга чакырабыз", - диелә белдерүдә.

**ТАНЫЛГАН ГАЛИМ СУХАЙЛ ТАРМАХОМЕД КАЗАНГА ӨЧ КӨНЛЕК ВИЗИТ ЯСАДЫ**


***Беренче көнне ул рус телендә язылган "Современные фетвы" китабын тәкъдим итте, визитының икенче көне Болгарга сәфәр кылуга багышланды.***

28 август көнне кичкә таба Әниләр мәчетендә С.Тармахомед Россия ислам университеты студентлары белән очрашты. Ул көнүзәк мәсьәләләргә карата үзенең фикерен җиткерде.

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

# ГЫЙЛЕМ ЭСТӘП КЫТАЙГА...

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*



"Гыйлем эстәүче - гыйлеменә ирешер, гыйлемгә ирешкәч, гөнаһ кылудан куркыр". (Хәдис)

Бар заманнарда да гыйлемгә омтылуларыннан көнләшерлек, алардан үрнәк алырлык кешеләр булган. Мисал өчен, урта гасырлар Шәрыкның гыйлем өлкәсендәге казанышлары гаҗәпләнерлек: Әбүгалисина, әл-Бируни, имам әл-Газзәли, Зәкәрия шәех, әл-Әнсари, имам Әбу Хәнифә һәм башка галимнәрнең исемнәре бар дөньяга билгеле...

Европада Авиценна исеме белән билгеле Әбүгалисина урта гасырлар фәне үсешенә зур өлеш керткән. Ул бик күп хезмәтләр язган, аларның ике йөздән артыгы бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән. Әбүгалисина күп өлкәләрдә, аеруча табигать фәннәре өлкәсендә, бигрәк тә тыйб белемендә (медицинада) зур белемнәргә ия булган. Нәкъ менә ул беренче булып чума (ваба) авыруларын тасвирлап язган, менингит, шикәр авыруы, ашказаны җәрәхәте (язва) кебек авыруларның барлыкка килү сәбәпләрен һәм аларны дәвалау ысулларын анализлаган...

Әл-Бирунины фәннең төрле өлкәләре - физика, химия, география, математика, астрономиядә күпсанлы ачышлары өчен энциклопедист галим дип атыйлар... Бу ил тормышының күп якларын яктырткан "Һиндстан" китабы аның билгеле хезмәте булып исәпләнә. Ул гарәп, юнән (грек), бәрбәрә, фарсы, санскрит телләрен, Рим империясе вакытындагы Сүрия язмаларын белгән.

Имам Әбу Хәнифә исә тирән белемнәре белән генә түгел, ә бик яхшы холкы белән дә дан алган, дин тәгълиматында зур уңышларга ирешкән. Шул ук вакытта ул аскетларча тормыш алып барган.

Гыйлем алуның мөһимлеге Рәсүлебез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) хәдисләрендә дә ассызыклап әйтелгән:

"Гыйлем - Исламның җаны һәм диннең нигезедер";

"Гыйлем эстәүчегә Аллаһ җәннәткә юлны җиңеләйтер";

"Гыйлем эстәү - Аллаһка сөннәт намаздан да якынрактыр".

Хәзерге заман кешесенә белем алу омтылышында ниндидер каршылыклар килеп чыгуы бөтенләй мөмкин түгел кебек. Тиешле мәгълүматны хәзерге вакытта төрле чыганаклардан: массакүләм мәгълүмат чараларыннан (телевидение, газета-журналлардан), интернеттан, күпсанлы курсларда, уку йортларында укып һ. б. алырга була. Шул ук вакытта күз алдыбызда гаҗәеп күренеш-хәл: нинди генә белем алуга булса да омтылышның гомумән сүлпән булуы (дини белемгә карата гына түгел) күзәтелә. Мондый вазгыять аеруча яшьләр арасында көчле, алар мәгълүматны интернеттан алалар (шунысын да мөһим дип исәплим: аларның бу мәгълүматына танышу сайтларындагы яңалыклар, модалы тенденцияләр, яңа уеннар, төрле шаярту-шаярышулар һ. б. керә). Шул ук вакытта: "Кирәк булганнныарны укырга әле мин һәрвакыт өлгерермен, мин әле яшь, минем барысы да алда", - дип исәпләүчеләр ялгышалар. Рәсүлебез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) үзенең хәдисләрендә: "Картлык килгәнче яшьлегеңнең кадерен бел", - дип әйткән.

Танышларымнан еш кына "Өлгерермен әле!" яки "Минем ни дә булса өйрәнергә хәзер вакытым юк әле" кебек фразалар ишетергә туры килә. Кайвакыт мин үзем дә мөһим эшләрне соңыннанракка калдырып куям, ә "соңыннан" буш вакыт табуы тагын да катлаулырак була. Шуңа да үзебезнең карамакта булган хәзерге, бүгенге вакытны тиешенчә файдаланырга тырышырга кирәк. Безнең өчен иртәгәге көн булырмы-юкмы, уйлаганыбызны без тормышка ашырырга өлгерербезме-юкмы икәнен беребез дә белми. Бу бигрәк тә иман, дин мәсьәләләренә кагыла.

Ислам дарелфөнүннәрендә (университетларында) дөньяви фәннәр дә укытыла. Бу - әлеге белемнәрнең, хәзерге вакытта, мөселманнар өчен мөһим икәнен ассызыклый. Безнең тәртибебезгә, безнең белем дәрәҗәбезгә бәя бирелеп, башка дин тарафдарларында Ислам турында фикер урнашып кала.

Элекке вакытта ата-аналар балаларын зур хөрмәткә ия булган гыйлем ияләренә укытырга бирә торган булганнар. Кытай мәкале: "Бер акыллы кеше белән гәп кору, бер ай китаплар өйрәнүгә тиң", - ди. Әйе, бүгенге көндә кайда дөреслек, кайда хак, кайда ялган, кайда алдап тагылган, калыплашкан кыйммәтләр икәнлеген төшенү читен. Һәм шуның өчен дә, кемнәрнеңдер кулында "курчак" булмас өчен, кемнәрнеңдер "ышандырырлык" ялган үгет-нәсыйхәтләре буенча хак юлдан язмас өчен, без укырга, хакыйкатькә төшенергә тиешбез, моның өчен, Рәсүлебез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) хәдисендә әйтелгәнчә, хәтта, Кытайга барырга кирәк булса да.

Кытай дигәннән, ул илнең атаклы фәлсәфәчесе Конфуций белемгә өч төрле юл илтә ди: "Фикер йөртү юлы - иң затлысы, кемгәдер иярү юлы - иң җиңеле, тәҗрибә юлы - иң ачысы". Бу фикерләрнең дәвамы буларак: "Уйламыйча гына күбрәк укыган саен, сез үзегезнең бик күп белүегезгә инана барасыз, ә укыганда никадәр күбрәк уйлансагыз, сез үзегезнең әлегә бик аз белүегезгә шулкадәр үк дәрәҗәдә төшенә барасыз", - дип язган Көнбатышның акыл иясе Вольтер.

Ислам традициясендә һәм безнең милләтебездә белем остаздан үз укучысына бирелә, һәм шул рәвешле ныклы, силсилә куәтендәге хакыйкый гыйлем үзенең куәтен югалтмый. Бу очракта силсилә булганда, ялган белем, хаталар һәм софистик алыштырулар булуы мөмкин түгел. Шуның өчен дә ислам традициясендә иҗазәт зур әһәмияткә ия булып тора.

Йомгаклап әйткәндә, барыбызга да (аеруча яшүсмерләргә) шуны телисе килә: исәпле вакытны әрәм итмәгез, аны белем алуга файдаланыгыз.

Укыгыз, өйрәнегез, чагыштырып фикер йөртегез. Вакыт - кире кайтарып булмый торган Аллаһның иң зур бүләкләренең берсе ул.

***Айдар хәзрәт КАРИБУЛЛИН, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең фән һәм мәгариф бүлеге белгече***

**Тарихчылар фикеренчә, Госман хәлифә вакытында уртак төгәллеккә кителгән Коръән дүрт нөсхәдә төзелә. Аның беренчесе - Мөсхаф-имам дип исем алганы - Мәдинәдә калдырылган, ә калганнары Куфа, Басра, Шам (Сүрия) шәһәрләренә җибәрелгән.**

Күп кенә тикшерүчеләр фикеренчә, Мәдинәдә калдырылган нөсхә Әндәлүзгә күчерелгән була. Аннан соң - Мароккога, ә 1485 елда ул Сәмәркандка барып эләгә. 1869 елда Россия галимнәре аны Санкт-Петербургка алып китәләр, ул анда 1917 елга кадәр була. Совет хакимияте вакытында манускрипт кире кайтарыла: 1924 елда ул Ташкентка күчерелә.

Беренче җыентыклар бик җентекләп төзелсәләр дә, аларда диакритик нокталар һәм сузыкламалар (сузык авазларны аңлатучы тамгалар) булмаган.

Беренче этапта текстка сузыкламалар урнаштырылган. Басра губернаторы Зыяд бине Сөммәя (672 елны вафат) фәрманы буенча, бу эшне гарәп теле буенча билгеле белгеч Әбу бине Әсвад әд-Дуали (688 елны вафат) җитәкчелегендә утызлап язу-сызу эшен башкаручы хезмәткәр башкарып чыга. Әл-Хәлил бине Әхмәд (791 елны вафат) вакытында, ул сузыклар өчен өстәмә тамгалар (һәмзә, тәштит һ. б.) кертелгәч, сузыкларны урнаштыру хәзерге рәвешен алган.

Икенче этапта диакритик нокталар куела, кыска һәм озын сузыклар өчен тамгалар эшләнә. Гыйрак хакиме әл-Хәҗҗаҗ бине Йосыфның (714 елны вафат) фәрманы буенча бу мәсьәләне Насыйр бине Асым (707 елны вафат), Яхъя бине Ягамур (746 елны вафат) башкарып чыга. Шул вакытта инде Коръәнне утыз өлешкә бүлә торган билгеләр (җузлар) кертелә. Бу очракта гамә-

**Мунчәли авылы кабаттан кадерле ул-кызларын, якын кардәшләрен, дус-ишләрен үзенә җыйды. 25 август көнне үткәрелгән милли җыен авыл тарихында гына түгел, милли әдәбият, сәнгать өлкәсендә дә эз калдырырлык вакыйгаларга бай булды.**

Быел республикабызда билгеләп үтелә торган Коръән елы кысаларында оештырылган җыен Коръән укучы яшүсмерләрнең зур ярышы белән башланып китте. Анда 30 дан артык бала үз көчен сынады. Мөнбәргә 8 яшьтән алып 12 яшькә кадәр һәм аннан да зуррак кызлар, егетләр менде. Максат бер - Коръәнне дөрес итеп уку. Татарстан хатын-кызларының "Мөслимә" иҗтимагый оешмасы рәисе Әлмира апа Әдиятуллинаның да катнашуы нур өстенә нур булды. Мәртәбәле жюри составында ТР Дәүләт Советы депутаты Фәрит Мифтахов, ТР мөселманнары Диния нәзарәте вәкиле Нияз Сабирҗанов, башкалабыздагы Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Чуаштан Республикасыннан Мансур хәзрәт килгән иде. Ярыш районда беренче карлыгач булуына да карамастан, мәртәбәле, колачлы булды. Район мәчетләре каршында эшләп килгән ял көне мәдрәсәләренә йөрүче балалар да, Чуаштан Республикасыннан, Самара өлкәсеннән һәм республикабызның төрле районна-

# КАПКА ТӨБЕНДӘ

(бәян-вәгазь)

*(Дәвамы. Башы газетабызның 5-6, 8 нче саннарында.)*

Казан мәчетләрендә кешенең күп булуына күнеккән Айдар намаз тәмамлануга картлардан:

- Мәчет һаман шулай бушмыни? - дип сорады.

- Җомга көнне 6-7 кеше җыела үзе, ә башка көннәрне халык мәчеткә йөрми, - диде Кәримулла хәзрәт.

- Әйтергә, чакырырга кирәк, - дип ачынып борчылуын белдергән егеткә Гарәфетдин бабай ахшамга кадәр булган хәлне исенә төшерде:

- Үзең шаһит, дәштек, чакырдык, әмма алар бит Тәгъзимә апаң кебек - чукрак. Аерма шунда гына: әби колакка каты булса, боларның калебләре саңгырау, күңел күзләре - сукыр... Шуңа хак сүзне ишетмиләр, тугры юлны күрмиләр, үзләре өчен бик кирәкле булган нәрсәләрнең файдасын аңламыйлар...

- Әле монда килер алдыннан гына бер вәгазь китабында шундый



нәрсә укыдым, - диде кызуланып Айдар. - "Мәчет ул - Аллаһ йорты, шуңа күрә анда килгән кеше Аллаһның кунагы була". Тагын шуны укыдым: буш торган мәчет бөтен мәхәллә халкына ләгънәт кылып торыр икән...

- Булыр-булыр, - дип ризалашты Кәримулла хәзрәт. - Әнә күрше авылда мәчеткә кеше ничек күп йөри. Анда кәсеп тә яхшы, аракы эчүчеләр дә юк диярлек, тормышлары бәрәкәтле, үз көенә җайлы гына бара. Ә бездә? Өй аралаш исерек, яшьләр үзләрен кая куярга белмичә трай тибеп йөри. Ул сугышу, ул сүгенү, урлашу, зина... Ю-ук, юк ул бездә тәртип. Кайчан булачагын да чамалый торган түгел...

Шулай сөйләшә торгач, күпме вакыт узганы сизелми дә калды. Мәчеттән урамга чыкканда инде караңгы иде. Баганалардагы янмаган лампалар өчен дә яктыртам дигән сыман, яп-якты ай авыл урамын нурга күмгән. Бабасы белән икәү генә калудан файдаланып, Айдар үзен борчыган бер соравын бирә:

- Бабай, әйт әле син миңа: нигә безнең әби Мәрфуга апага гел шулай кычкыра?

- И улым, бу бит әбиең түгел - аның хәсрәте кычкыра. Исерек белән яшәү әллә җиңел дип беләсеңме? Миңсылуыбыз балалар хакына гына түзәм дип торды моңарчы аларда, алга таба ни булыр... Ә соравың дөрес. Аннары шунысы да бар: баланың тормышы рәтсез булуда, аның шәхси бәхетсезлегендә ата-анасының да гаебе булырга мөмкин. Бәлки, Аллаһ каршында ниндидер хатабыз, гөнаһыбыз бардыр. Шуңа күрә зарланырга, кемнәндер гаеп эзләргә түгел, тәүбәгә килеп, Аллаһтан ярлыкауны сорарга кирәк. Барыбызга да.

Гарәфетдин бабай бераз сөйләшмичә барды. Бу вакытта ул Мәрфуганың яшь чакта авылның иң чибәр кызы, аның яшьлек мәхәббәте булуын, читкә эшкә китүе сәбәпле, аның белән кавыша алмавын, кайткач та... Юк, барысын да Айдарга сөйләү ярамас. Сер булып калсын.

Шулай эчтән генә яшьлек хатирәләрен яңартып алып, Гарәфетдин бабай сүзен дәвам итә:


- Мәрфуга апаң кешегә сиздермәсә дә, ничек кайгыруын беләм мин аның. Күп күрде инде ул, бичара. Карты да бик эчкән бит. Айный алмыйча эчеп үлде дә. Ә аның кебекләр күпме бездә! И-их!..

Менә Гарәфетдин абый белән Айдар өйләренә кайтып та җиттеләр. Бабай, бераз гына хәл алам дип, капка төбендәге эскәмиягә утырды.

***Ришат КУРАМШИН, Кукмара мәдрәсәсе мөдире***

2012 ЕЛ - ТАТАРСТАНДА КОРЪӘН ЕЛЫ

# КОРЪӘН – ИСЛАМНЫҢ ИҢ ТӨП ЧЫГАНАГЫ



ли максат нигезендә шундый карарга киленә, чөнки мондый бүленеш рамазан аендагы төнге намазларда Корьән укуны җиңеләйтә. Хәзерге басмаларда һәр җузны гадәттә тагын ике өлешкә (хизбе) бүләләр, ә һәр хизбене тагын дүрт чиреккә (руб) таркаталар.

Корьәннең төзелеше. Корьән тексты сүрә һәм аятьләргә бүленә.

Аять - бер яки берничә тәгъбирдән торган өлеш. Корьәндәге иң озын аятьләрнең берсе - икенче сүрәнең ("Бәкарә (Сыер)") 282 нче аяте. Иң "кыйммәтле" аять булып та шул сүрәнең 255 нче аяте - "Аятел-Көрси" исәпләнә. Анда Исламның төп традицияләре һәм Аллаһы Тәгаләгә хас сыйфатларның бөеклеге, чиксезлеге бәян ителә.

Корьәннең беренче җыентыкларында, бүгенге басмалардагы кебек, аятьләр бер-берсеннән тамга белән аерылып куелган булмаганнар, шуңа да, галимнәр арасында Изге Китаптагы аятьләрнең саны буенча кайбер фикер каршылыклары туган. Аларның барысы да Китапта 6200 дән артык аять барлыгын таный. Төгәлрәк саннарны күрсәткән вакытта бу белгечләр арасында бер фикер юк, тик бу саннарның төрлелеге катгый әһәмияткә ия түгел: алар хакыйкый сүзләрнең эчтәлегенә карамастан, аны бары тик аятьләргә ничек итеп бүлүгә генә кайтып кала.

Хәзерге Корьән басмаларында (Согуд Гарәбстаны, Мисыр, Иран) 6236 аять; бу Гали бине Әбу Талиб вакытында башланып киткән Куфа традицияләренә туры килә. Дин белгечләре арасында аятьләрне сүрәләрдә ничек урнаштыру буенча фикер каршылыклары туганы юк, алар Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) үзе сөйләгән эзлеклелектә урнаштырылганнар.

Сүрә - Корьәннең аятьләр төркемен берләштерә торган бүлек. Бу гарәп сүзе "биек урын" (гарәпчәдәге сур - дивар, койма сүзеннән) дигәнне аңлата. Мондый бәяләмә шуның белән аңлатыла: Корьән бүлекләрендәге сүзләр, Аллаһы Тәгалә күпме тели, шулкадәр күләмгә җиткәнгә кадәр, бер-берсенә тоташалар. Башка тәфсир буенча, бу исем Корьәндәге хакыйкать мәгънәсенең бөеклеген, төзеклеген ассызыклыйлар.

Корьән 114 сүрәдән тора, аларны шартлы рәвештә Мәккә һәм Мәдинә сүрәләренә бүләләр. Күп кенә галимнәр фикеренчә, Һиҗрәткә кадәр иңдерелгән бар сүрәләр дә - Мәккә, ә Һиҗрәттән соң иңдерелгәннәре - барысы да, гәрчә ул Мәккәнең үзендә иңдерелгән булса да, Мәдинә сүрәләренә карый; мәсәлән, Мәккәгә соңгы хушлашу хаҗы вакытында иңдерелгәннәре. Мәдинәгә күченгән вакытта иңдерелгән аятьләр Мәккә аятьләре булып исәпләнәләр.

Корьәндә сүрәләрне урнаштыру тәртибен Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) үзе билгеләгән. Ибне Габбас сүзләренә нигезләнеп, Пәйгамбәргә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) нинди дә булса сүрә иңдерелгән һәрбер вакытта, ул, язу эшләрен алып баручыларның берсен чакырып алып: "Бу сүрәне шул турыда сөйләнгән урынга урнаштырыгыз", - дип әйтә торган булуын сөйлиләр. Шулай ук Зәед бине Сабитның: "Без Рәсүлуллаһ (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) белән янәшә тордык һәм күн кисәкләрендә Корьәнне төзедек", - дип белдерүен дә ирештерәләр. "Төзү" дигән вакытта сүрәләрне Пәйгамбәр (аңа Аллаһының рәхмәте һәм сәламе булсын!) әйтүе буенча урнаштыру күз алдында тотыла. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) урнаштыру тәртибен Җәбраил фәрештәдән (Аллаһ аны ярдәменнән ташламасын!) алган, хәдисләрнең берсендә Җәбраилнең (Аллаһ аны ярдәменнән ташламасын!): "Шул аятьне шул урынга урнаштырыгыз", - дип әйткән сүзләре язылган. Җәбраил фәрештә (Аллаһ аны ярдәменнән ташламасын!) Аллаһы Тәгаләнең боерыгын үтәвендә бер шик тә юк.

Сүрәләр Пәйгамбәргә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) иңдерелгән тәртиптә урнаштырылганнар. Корьән Мәккәдә иңдерелгән "Фатиха" сүрәсеннән башлана. Бу сүрәнең җиде аяте ислам тәгълиматының нигез таләпләрен үз эченә туплаган, шуңа да ул "Изге Язмаларның анасы" исемен йөртә. Алардан соң Мәдинәдә иңдерелгән, шәригать кануннарын аңлаткан озын сүрәләр килә. Мәккә һәм Мәдинәдә иңдерелгән кыска сүрәләр Корьәннең соңгы битләрендә урын алган. Бу сүрәләр кыска аятьләрдән гыйбарәт һәм алар дини йолаларны башкарган вакытта укыла.

Сүрәләрнең исемнәренә килгәндә исә - алар соңыннанрак кертелгәннәр. Әмма мөселман галимнәре, Корьәннең теге яки бу урыны турында сөйләгән вакытта, сүрәнең исемен (тәртип санын түгел) кулланалар. Кайбер сүрәләр кабатланмас исемнәр йөртә: мәсәлән, "Нәхел (Бал корты)" - Корьәндә бал кортлары турында сүз барган бердәнбер урын 16 нчы сүрәнең 68-69 нчы аятендә; "Шөгарә (Шагыйрьләр)" - шагыйрьләрне бердәнбер искә алу урыны 26 нчы сүрәнең 224-227 нче аятьләрендә һ. б.

***Гаптрәүф НУРИЕВ,***
***филология фәннәре докторы;***
***Нияз САБИРҖАНОВ***

# "Туфанга сөйләрмен дигән уй туды..."

рыннан килүче укучылар да, Корьән сүзләренә тыйнаклык, игътибарлылык күрсәттеләр.

Ярышны Татарстанның көньяк-көнбатыш төбәге казые, Чүпрәле районы имам-мөхтәсибе Фәһим хәзрәт һәм Иске Чокалы мәчете имамы Рамил хәзрәт алып барды. Җиңүчеләргә Сочи шәһәрендә яшәүче якташыбыз Илдус Юнысов иганәчелек итте. Җыенны оештыручы Илмир Измайлов әлеге кыйммәтле бүләкләрне һәм мөхтәсибәт тарафыннан бирелгән Мактау грамоталарын тапшырды. Ярышта "Корьән уку остасы", "Иң оста Корьән укучы, "Гүзәл махраҗ", "Нәфис тавыш", "Яттан белүчеләр", "Инсафлы", "Тәвәккәл" дигән номинацияләрдә көч сынаштылар. Иңиңнәргә урыннар да билгеләнде. Малайлар арасында Радик Сафиуллин (Зур Чынлы) - беренче, Ильяс Сафиянов (Шыгырдан) - икенче, Дәүләт Нигъманов (Шыгырдан) өченче урынны яулады. Кызлар арасында: Алсу Айзәтуллова (Шыгырдан) - беренче; Илүзә Галләмова (Чишмә авылы) - икенче; Зөһрә Гыйбатдинова (Комсомол районы) өченче урын алды. Ярыш соңында сәхнәгә Дания Тулова менде. Ул беренче урынны алган Алсуга һәм ярышны оештыручы, Чүпрәле мөслимәләре берлеге рәисе Энҗе Шәрәфетдиновага динебезне үстерүдә зур өлеш кертүләре өчен истәлекле бүләк тапшырды, оештыручылар тарафыннан I, II, III урыннар алучы балалар кәрәзле телефоннар белән бүләкләнде.

Авыл җыенының төп өлешендә мәктәп янында район мәдәният йортында хезмәт итүче чибәр кызлар кунакларны ипи-тоз белән каршы алды. Мәктәп укучылары музыкаль монтажда ни өчен Туфан ага Миңнуллинны яратуларын шигъри юллар аша җиткерделәр. Район Башкарма комитеты рәисе Шәүкәт Алиуллов беренче мәктәпнең Мунчәлидә ачылуы, авылның укымышлы кешеләре шәһәрләргә юл алуын сөйләде.

Фәрит Мифтахов сүз алып, үзенең Туфан ага шәкерте булуын, милләтебезне, динебезне үстерүдә аның эшен дәвам итәчәген әйтте. Быелның 2 маенда вакытсыз бакыйлыкка күчкән Туфан аганың якты истәлегенә бик күп җылы сүзләр әйтелде. Г.Камал театры артистлары Рузия Мотыйгуллина, Ринат Таҗетдинов, Буа сатира театры җитәкчесе Раил Садриев аның әсәрләреннән өзекләр күрсәтте. Җыенны "ТНВ" каналында "Хәерле иртә" тапшыруын алып баручылар - Илдар Кыямов белән Миләүшә Сибгатуллина милли җанлы Туфан аганың мәдәният өлкәсендә генә түгел, депутат булырак та халкыбызга бәяләп бетергесез хезмәт кылуы турында җиткерде. Мунчәлидәге мәһабәт мәктәп бинасын салдыруда да аның өлеше зур булган. Татарстанның атказанган урманчысы, авылдашлары Ирфан Халитов та: "Бу мәктәп аңа үзе бер һәйкәл", - диде. Туфан ага Миңнуллинга истәлекле мемориаль такта ачуга ярдәм иткән район башлыгы Тимур Нагумановка, "Таттрансгаз"ның баш хисапчысы Венера Әхмәтовага олы рәхмәтләрен белдерде. Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев: "Кеше дөньядан киткәч аның урыны буш кала. Бу бушлык Туфан агадан соң тагын да зуррак булды.

***(Ахыры 4 нче биттә.)***



# "Туфанга сөйләрмен дигән уй туды..."

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

Аның исемен мәңгеләштерүне сез беренче башлап җибәрдегез, кулыгыз җиңел булсын", - диде. Туфан аганың җәмәгате Нәҗибә Ихсанова: "Аның белән Мәскәүдә 5 ел бергә укыдык. Ул безгә иҗади ризык әзерләгән бәрәкәтле бәндә булды. Ул кызыбызның әтисе генә түгел, иҗатымның чишмә башы да. Татар халкы иҗади халык, беркайчан да югалып калмый. Әле генә, кайткач Туфанга сөйләрмен дигән уй туды", - диде ул. Якташыбыз Ринат Таҗетдинов та: "Әгәр ул яхшы әсәрләр иҗат итмәгән булса, без зур исемнәргә лаек булмас идек", - дип үз фикерен җиткерде.

Истәлек тактасын Шәүкәт Алиуллов һәм Туфан аганың җәмәгате Нәҗибә апа ачты. "Мунчәли мәктәбен төзүгә, авылның тарихи-мәдәни мирасын саклап калуда зур өлеш керткән бөек татар драматургы, ТР Дәүләт Советы депутаты Туфан Абдулла улы Миңнуллин истәлегенә" дигән сүзләр язылган ул тактага.

Җыенда район музыка мәктәбенең "Умырзая" халык уен кораллары ансамбле чыгыш ясады. Авылның иң оста пешекчеләре кунакларны коймак, чәй белән сыйлады. Авылның тарихын бай чагылдырган күргәзмә дә үз йөзен ачты.

Өйлә намазыннан соң зират чистартып кайткан авыл халкын, кунакларны рәт-рәт булып тезелгән өстәлләр сый-хөрмәт белән каршы алды. Халык сыйланган арада мәртәбәле кунаклар беренче мәртәбә Мунчәли укулары оештырып, тарихи мирасны барладылар. Анда галимнәрдән Нурмөхәммәт Хисамов, Марсель Әхмәтҗанов, Наил Таиров, Рафикъ Насыйров, Рәшид Маликов чыгыш ясады. Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев һәм Чүпрәле районы үзешчәннәре Фәсәхәт Хөсәенова, Надирә Шәрәфетдиновалар мөнәҗәт әйтте.

Үткәннәрен барлаган халыкның киләчәге була. Мондый уйхыяллар мәдәният йортында башланып киткән "Шәҗәрә" дигән очрашуда да дәвам итте. Алар арасында Самара һәм Түбән Новгород якларыннан Мунчәли авылына күчеп килүчеләр дә бар иде. Авылның төп мәйданын сәүдә нокталары әйләндереп алды. Авылыбыздан чыккан җырчылар халыкны җыр-моңга төрде. Авыл бәйрәмендә Татарстанның халык артисты Габделфәт Сафин, күренекле сәнгать осталары Әлфия Рамазанова, Айрат Җамалетдинов һ. б. катнашында зур бәйрәм концерты, милли көрәш, ат чабышы төн уртасына кадәр дәвам итте һәм аллы-гөлле салют балкышлары белән тәмамланды. Тарихи-мәдәни мирасны барлау елы булачак, әлеге бәйрәм зур тарихи әһәмияткә ия

**Сания ШӘРАПОВА,**
**Чүпрәле районы**

# Гыйбадәт кылганда игътибарым гел читкә юнәлә

СОРАУ-ҖАВАП

***Миңа билгеле бер очракларда Аллаһка инануымны саклап калу үтә авыр: мәсәлән, мин тәһарәт алырга ниятләгәндә яки тәһарәт алганда минем күңелемә бик зур көч тәэсирендә чит-ят уйлар керә. Мин моның белән үземчә көрәшергә тырышып карыйм, ләкин миндә мондый халәт шактый дәвамлы була. Миңа бу хәлдән ничек котылырга? Ярдәм итегезче!..***

**Исемемне**
**һәм адресымны язмыйм**


**Сезнең соравыгызга Татарстанның көньяк-көнбатыш төбәге казые, Чүпрәле районы имам-мөхтәсибе Фәһим хәзрәт ӘХМӘТҖАНОВ җавап бирә:**

- Үзеннән-үзе туа торган чит-ят уйлар гөнаһ түгел, әмма аларны уйга чумып һәрьяклап "тикшерү" гөнаһ һәм бу бик еш кабатлану сәбәпле, мөселман кешесе кяферлеккә кадәр "барып җитәргә" мөмкин. Башыгызга бәйләнчек (вәсвәсә) уйлар "кереп оялаган" чакта сезгә нинди дә булса башка берәр мәсьәләгә күчәргә, хәтерегездә яхшы сакланып калган вакыйгаларны яңартырга, һичьюгы, дөньяда безнең көннәрдә бара торган яңалыкларны күз алдыннан үткәрергә кирәк.

Әгәр дә сезнең күңелегезгә тынгылык бирми торган конкрет сорауларыгыз бар икән, аларга мөстәкыйль рәвештә җавап эзләргә тырышмагыз: иң яхшысы - мәхәлләгездәге абруйлы, тәҗрибәле дин әһеленә мөрәҗәгать итү. Ул имамнан канәгатьләнерлек җавап ала алмасагыз, төбәк казыена барыгыз. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенә караган мәхәлләләр, географик картада урнашуларына карап, 9 төбәккә бүленеп эшли. Сезнең район кайсы казыяткә карый икәнен мөфтиятнең рәсми сайтына кереп белә аласыз: www.dumrt.ru/kaziyat.

Биш вакыт намазларыгызны һәм җомганы үтәгәннән соң: "Я Раббым! Миңа вәсвәсә уйлардан һәм шик-шөбһәләрдән арынырга Үзеңнең ярдәмеңне бирсәң иде", - дип дога кылыгыз.

Коръәндәге "Бәкара (Сыер)" сүрәсенең 255 нче аятен - "Аятел Көрси"не, "Ихлас", "Фәлак (Таң ату)", "Нәс (Кешеләр)" сүрәләрен ешрак укыгыз. Бу сүрәләрне шулай ук суга укырга һәм аннан соң ул суны эчәргә кирәк; әлбәттә, ул Зәм-зәм суы булса яхшырак. Ник дигәндә, аның шифасы күбрәк булыр, чөнки Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) хәдисендә әйтелгәнчә, ул бар нәрсәдән дә сихәт бирүче дару булып тора һәм аны шуның өчен эчәләр дә.



# Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 1.09.12 | 4:19 | 5:49 | 13:02 | 17:25 | 19:37 | 21:07 |
| Якшәмбе | 2.09.12 | 4:21 | 5:51 | 13:02 | 17:24 | 19:35 | 21:05 |
| Дүшәмбе | 3.09.12 | 4:23 | 5:53 | 13:02 | 17:22 | 19:32 | 21:02 |
| Сишәмбе | 4.09.12 | 4:25 | 5:55 | 13:02 | 17:20 | 19:29 | 20:59 |
| Чәршәмбе | 5.09.12 | 4:26 | 5:56 | 13:02 | 17:19 | 19:27 | 20:57 |
| Пәнҗешәмбе | 6.09.12 | 4:28 | 5:58 | 13:02 | 17:17 | 19:24 | 20:54 |
| Җомга | 7.09.12 | 4:30 | 6:00 | 13:02 | 17:15 | 19:22 | 20:52 |
| Шимбә | 8.09.12 | 4:32 | 6:02 | 13:02 | 17:13 | 19:19 | 20:49 |




# Ислам һәм демократия

**2012 елның язында Американың "Pew Research Center" социологик хезмәте тикшеренүләр уздыра. Тикшеренүләр Тунис, Мисыр, Иордания, Төркия, Пакьстан, Ливан һ. б. мөселман илләрендә үтә. Бу илләрдә "гарәп язы" агымында булып үткән иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр социологларны бик тә кызыксындыра.**

Мәсәлән, Тунис һәм Мисырда беренче ирекле сайлаулар нәтиҗәсендә исламчылар ничек җиңеп чыга алганнар? Бу үзгәрешләр шушы илләрдә яшәүче кешеләрнең демократиягә карашларын ни дәрәҗәдә үзгәрткән? Сораулар күп. Тикшеренүләр түбәндәге нәтиҗәгә китерганнәр.

"Демократия" термины Көнбатышта барлыкка килүенә дә карамастан, кире кагылмый. Югарыда санап үтелгән мөселман илләрендә үткәрелгән сорашулар буенча, ил белән идарә итүдә демократияне якынрак күрүчеләрнең саны Туниста - 63 %, Мисырда - 67 %, Иорданиядә - 61 %, Төркиядә - 71 % тәшкил итә. Демократияне иң якын күрүчеләр Ливанда яши - 84 %. Пакьстанда исә демократияне 42 % кеше генә хуплый.

Социологик тикшеренүләр нигезендә демократия шәригатькә каршы куелган булу сәбәпле, демократияне хуплап яки кире кагып, кешеләр ил белән идарә итүдә һәм законнар чыгаруда дөньяви формага үзләренең мөнәсәбәтләрен билдергәннәр.

Бу тикшеренү нигезендә түбәндәге нәтиҗәләр чыгарылган: Пакьстанда юридик законнарның шәригать кануннарына туры килүен хуплаучылырның саны - 82 %. Иордания һәм Мисырда да шәригатьне яклаучылар бар - 72 % һәм 60 %. Ләкин бу ике илнең үзенчәлеге булып, анда яшәүче халыкның шәригать кануннарын кертүне хуплау белән беррәттән, ил белән идарә итүдә демократик форманы якын күрүләре тора. Шәригать кануннарын кертүне яклаучылар саны аз булган илләр - Тунис (23 %), Төркия (17 %) һәм Ливан (17 %). Ливанда яшәүчеләрнең 40 проценты христиан диненнән булуларын да онытмаска кирәк. Шуңа да бу илдә ир-ат һәм хатын-кыз хокуклары бертигез булырга тиеш дип исәпләүчеләр саны 93 % тәшкил итүе гаҗәп түгел. Шул ук вакытта Мисырда алар саны 58 % кына.

Тикшеренүдә шулай ук "Әл Каидә"гә мөнәсәбәтләрне белү дә максат итеп куелган. Бу террорчы оешманы яклаучылыр саны Мисырда - 18 %, Туниста - 16 %, Пакьстанда - 13 %.

**Айдар ХӘЙРЕТДИНОВ,**
**фәлсәфә фәннәре кандидаты**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 9 (152) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9414.
**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 30 август көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллланудан сакланыгыз!**